| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.01.2013 г.Казань № 20

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2013 елның 28 февралендә 1829 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 16 июлендәге 567 номерлы боерыгы белән расланган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының (алга таба – Россия ГТХМ) «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга бердәм үрнәктәге таныклыклар бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 18 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга бердәм үрнәктәге таныклыклар бирү тәртибенә Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының «Россия ГТХМ 2012 2009 елның 18 сентябрендәге 540 номерлы боерыгы белән расланган «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга бердәм үрнәктәге таныклыклар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 30 июлендәге 455 номерлы боерыгы белән үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 16 июлендәге 567 номерлы боерыгы белән расланган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга таныклык (таныклык дубликаты) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

(алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты»;

2.5 пунктның 2 графасында җиденче абзацны төшереп калдырырга;

2.6 пунктның 2 графасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданин таныклык алуны сорап мөрәҗәгать иткәндә һәм торак пунктта яшәү турында документлар тапшырганда Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган торак пунктлар исемлегенә кертелгән торак пунктта яшәү турында документлар тапшырганда, шушы торак пунктта яшәүчеләргә радиация йогынтысын күрсәткән атом-төш сынаулары көнен үз эченә алмаган чорда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 15 ноябрендәге 634 номерлы карары белән расланган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә алынган суммар (тупланган) нәтиҗәле доза нурланыш алу кагыйдәләре нигезендә гражданнарны радиация йогынтысына дучар булган затлар категориясенә кертүне билгели торган оешмадан Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә алынган (тупланган) радиация дозасы турында бәяләмә.»;

3 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.2 пунктчада «6» санын «7» санына алмаштырырга;

3.2 пунктта икенче абзацта «дәүләт хезмәте» сүзләреннән сод «гариза кәгазен бирә, кирәк булган очракта, гариза кәгазен тутыруда ярдәм итә» сүзләрен өстәргә;

3.2 пунктының өченче абзацында түбәндәге эчтәлекле ике җөмлә өстәргә:

«Консультация алу өчен шушы Регламентның 2.5 п. күрсәтелгән документларның күчермәләре электрон рәвештә һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрелергә мөмкин.»;

3.3 пунктның 3.3.1 пунктчасының икенче абзацында «почта юлламасы итеп» сүзләреннән соң «яки электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша» сүзләрен өстәргә;

3.3 пунктта 3.3.2 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кирәкле барлык документлар булуын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә

(документларны тиешенчә рәсмиләштерү, документларда чистартылган, өстәп язылган, сүзләре сызылган урыннар һәм алдан сөйләшенмәгән башка төзәтү урыннары булу-булмавын) туры килүен тикшерә.»;

3.5 пунктның 3.5.1 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле яңа икенче - өченче абзацларны өстәргә:

«мөрәҗәгать итүче таныклык алу өчен мөрәҗәгать итеп, һәм торак пунктта яшәү турында документлар тапшырган очракта, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннанраслана торган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә радиация йогынтысына дучар булган торак пунктлар исемлегенә кертелгән торак пунктта яшәү турында документлар тапшырылган очракта, шушы торак пунктта яшәүчеләргә радиация йогынтысын күрсәткән атом-төш сынауларын уздыру көнен үз эченә алмый торган чорда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2004 елның 15 ноябрендәге 634 номерлы карары белән расланган Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә гражданнарны радиация йогынтысына дучар булган затлар категориясенә кертү кагыйдәләре нигезендә билгеләнә торган оешмага (алга таба – оешма) 6 нчы кушымта нигезендәге үрнәк буенча Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә суммар (тупланган) нурланыш дозасы турында бәяләмә бирү турында гариза җибәрә;

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә алынган суммар (тупланган) нәтиҗәле нурланыш дозасы турында бәяләмә алган очракта, документлар комиссиягә җибәрелә.»;

3.5 пунктның 3.5.1 пунктчасындагы икенче һәм өченче абзацларны, туры китереп, дүртенче һәм бишенче абзацлар итеп санарга;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затның (хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү»;

5.1 пунктның икенче абзацында «министр исеменә яки» сүзләреннән соң «кураторлык итүче министр урынбасары» сүзләрен өстәргә;

6 нчы кушымтаны 7 нче кушымта итеп санарга;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 нчы кушымта өстәргә:

«Семипалатинск полигонындагы
атом-төш сынаулары аркасында
радиация тәэсиренә дучар булган
гражданнарга таныклык (таныклык
дубликаты) бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентына 6 нчы кушымта

ҮРНӘК

Бәяләмә бирүче оешма бланкы

Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә нурланышның суммар (тупланган) нәтиҗәле дозасы турында № _____ бәяләмә

Әлеге гариза буенча бирелде ________________________________________
(Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы исеме, гариза белешмәләре)

әлеге гражданинга карата ____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), туган көне, ае, елы)

яши ______________________________________________________________________,
(даими яшәгән урын адресы)

ул түбәндә яшәгән вакытта
(кайда)___________________________________________________________________
(торак пункт, район, өлкә исеме)

19___ елның __________ башлап 19___ елның ________ кадәрге чорда Семипалатинск полигонында атом-төш сынаулары нәтиҗәсендә нурланыш дозасын суммар (тупланган) доза алырга мөмкин

__________________________________________________________________________
(нурланыш дозасын суммар (тупланган) доза: 5 сЗв (бэр) дәрәҗәсеннән артык, 25 сЗв (бэр) дәрәҗәсеннән артмый; 25 сЗв (бэр) дәрәҗәсеннән арта; 5 сЗв (бэр) дәрәҗәсеннән кимрәк)

Әлеге белешмәләр нурланыш дозасын исәпләү беркетмәсе нигезендә кертелде

__________________________________________________________________________,
(көне, беркетмә №)

түбәндәге нигезендә башкарылган

__________________________________________________________________________
(Кулланучылар хокукларын яклау һәм иминлек өлкәсендә күзәтчелек хезмәте тарафыннан расланган методик күрсәтмәләрнең аталышы һәм реквизитлары)

«__» _______________ 201_ел. ________________________________________
(бәяләмәне рәсмиләштерү көне) (вазыйфаи затның имзасы, инициаллары, фамилиясе)

Мөһер урыны».

Министр
А.Р.ШӘФИГУЛЛИН